**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“22” ноябрь 2025 ел. № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Федераль законның 45, 69 статьялар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 17 ноябрендә узган җыен нәтиҗәләре белән «Сез 2026 елда Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алмаштыру, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Әтнә торак пункты урам юлларын ремонтлау һәм ябу (вак таш сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Әтнә торак пункты урамнары территориясен төзекләндерү һәм чистарту (үләннәр чабу, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан, чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); балалар мәйданчыгы территориясен чистарту (үлән чабу, эш һәм хезмәт өчен түләү);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **220** (ике йөз егерме) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны **124** (йөз егерме дүрт) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы **110** (йөз ун) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 14 (ундүрт) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – **дөрес дип танырга**.

“Сез 2026 елда Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән

өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алмаштыру, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Әтнә торак пункты урам юлларын ремонтлау һәм ябу (вак таш сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Әтнә торак пункты урамнары территориясен төзекләндерү һәм чистарту (үләннәр чабу, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан, чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); балалар мәйданчыгы территориясен чистарту (үлән чабу, эш һәм хезмәт өчен түләү);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә - мәсьәләсен кабул итәргә.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе С.Н.Порфирьев